**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 апрель № 268

г. Казань

2015 елга Халык өстенлекләре Реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыруның тәртибе турында” 2007 ел, 19 нчы март, 90 нчы номерлы карарын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.02.2010 елдагы 87 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) тормышка ашыру максатларында, 2014 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган 2015 елга Халык өстенлекләре Реестрын расларга (алга таба – реестр).

2. Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнарына:

Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча чараларны Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнелүче дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге чараларны тормышка ашыруны мониторинглауны контрольдә тоту буенча җаваплы затларны боерык белән билгеләргә;

2015 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча башкарылган эш турында мәгълүматны, халык приоритетындагы төп проблемалар исемлеге кисемендә, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге” дәүләт бюджет учреждениесенә тапшырырга.

3. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары белән бергә Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру

буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эше барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары А.В.Песошинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\268.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 20 апрель, 268 нче
карары белән расланды

**2015 елга халык өстенлекләре реестры**

| Т/с | Өстенлек исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процентлар | Төп проблемалар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Халыкның керем һәм социаль ярдәм дәрәҗәсен күтәрү | 41,2 | түбән дәрәҗәдәге хезмәт хаклары, пенсияләр һәм пособиеләр;<br>диспропорциональ бүленә торган халык керемнәре;<br>җитәрлек санда булмаган эш урыннары;<br>түләве тоткарлана торган хезмәт хакы;<br>файдалана алырлык булуы түбән дәрәҗәдәге социаль хезмәтләр;<br>нәтиҗәле булмаган адреслы социаль ярдәм чаралары |
| 2. | Бәя ясау һәм тариф ясауны җайга салу | 38,7 | даими үсүче бәяләр һәм тарифлар;<br>икътисадый нигезләнмәгән бәяләр һәм тарифлар;<br>бәясе һәм сыйфаты туры килми торган товарлар һәм хезмәтләр;<br>торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләре югары булган йортның гомуми ихтыяҗлары;<br>формалаштырылуы ачык булмаган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр;<br>дәүләт ягыннан контрольнең булмаган торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлеге |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Торакның һәркем алырлык булуын тәэмин итү | 33,5 | урта һәм түбән керемле гаиләләр өчен торак сатып алуны күздә тота торган җитәрлек санда булмаган программалар;<br>үсеш алмаган дәүләт торак төзелеше;<br>процент акчалары югары куелган ипотека кредиты |
| 4. | Наркоманлыкка һәм эчкечелеккә каршы тору | 29,9 | наркотик чараларны кулланган һәм тараткан өчен җәзалауларның тиешенчә катгый булмаган системасы;<br>җитәрлек санда булмаган наркоманлыкны һәм эчкечелекне профилактикалау һәм дәвалау буенча нәтиҗәле программалар;<br>түбән нәтиҗәле наркотик матдәләр таратуга юл куймауга юнәлдерелгән чаралар;<br>алкоголь исереклеге хәлендә кылынган җинаятьләрнең күп саны;<br>сәламәт яшәү рәвешен алга сөргән һәм алкогольне күп куллануның һәм наркотикларны медицина кушмаганча куллануның тискәре нәтиҗәләре турында халыкка бирелгән мәгълүмат бирү буенча чараларның түбән нәтиҗәлелеге |
| 5. | Ришвәтчелек һәм коррупциягә каршы тору | 26,2 | җитәрлек дәрәҗәдә катгый булмаган ришвәтчелек өчен җәзалау системасы;<br>коррупциягә каршы сәясәтнең түбән нәтиҗәлелеге |
| 6. | Эшсезлек дәрәҗәсе киму | 23,2 | югары җитештерүчәнле эш урыннарының җитәрлек булмаган саны;<br>югары профессиональ белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар өчен стажировкалар оештыру системасының үсмәве;<br>кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә хакимият органнары игътибары җитмәү;<br>булган эш урыннарын хезмәт мигрантлары биләү |
| 7. | Җәмәгатьчелек иминлеген тәэмин итү | 22,8 | халыкның хокук саклау органнарына ышанычының түбән дәрәҗәсе; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | гражданнар яклануының түбән дәрәҗәсе;<br>йөртүчеләр һәм җәяүлеләр тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен еш сакламау;<br>алкоголь исереклеге хәлендә кылына торган җинаятьләрнең зур күләме;<br>чит милекне талау белән бәйле җинаятьләрнең зур күләме;<br>балигъ булмаганнар тарафыннан хокук бозулар |
| 8. | Әйләнә-тирә мохит торышын яхшырту | 17,9 | гражданнарның түбән экологик культурасы;<br>юлларда автомобильләр саны арту, аларның йортлар ишегалларында туплануы;<br>чүп эшкәртү буенча предприятиеләрнең җитәрлек санда булмавы;<br>агым суларны сыйфатсыз чистарту;<br>предприятиеләр тарафыннан атмосферага һәм суга зарарлы чыгармаларны башкару;<br>шәһәр территориясендә экологик яктан зарарлы производстволар булу;<br>җәмәгать урыннарында һәм ишегалларында чүп җыю буенча сыйфатсыз эшләр;<br>санкцияләнмәгән чүплекләр барлыкка килү. |